РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12. 11. 2012 № 118-п

Район предприятиеләре, учреждениеләре, бюджет оешмалары һәм авыл җирлекләре арасында якташыбыз Шәүкәт Хәсән улы Биктимеров истәлегенә багышланган "Театр фестивале"н оештыру турында

Район яшьләренең һәм хезмәт ияләренең буш вакытларын файдалы итеп оештыру максатыннан,

КАРАР БИРӘМ:

1. Байлар Сабасы шәһәр җирлегендә һәм авыл җирлекләрендә Шәүкәт Биктимеров истәлегенә багышланган "Театр фестивале"н үткәрергә.

2. "Театр фестивале"н үткәрү графигын, район оештыру комиссиясе һәм нигезләмәсен расларга.

3. Графикта күрсәтелгән предприятие, учреждение һәм бюджет оешмалары җитәкчеләренә хезмәт коллективларында эшләүче талантлы хезмәт ияләрен җыеп, аларның "Театр фестивален"дә катнашуын оештыруны тәэмин итәргә.

4. "Театр фестивале"нә репертуар сайлау буенча ярдәм күрсәтүне мәдәният йорты хезмәткәрләренә, район үзәк һәм авыл китапханәләренә тәкъдим итәргә.

5. "Саба таңнары" газетасы редакциясенә, "Саба дулкыннары" телерадиокомпаниясенә "Театр фестивале" барышын даими яктыртып баруны тәкъдим итәргә.

6. Районда булачак "Театр фестивале"ндә катнашучы коллективларга ярдәм итү өчен белгечлекләре туры килгән мәдәният хезмәткәрләрен билгеләргә.

7. Спектакльләрнең әзерлеген һәм авылларга чыгу өчен техника белән тәэмин итүне авыл җирлеге башлыкларына тәкъдим итәргә.

8. Аеруча яхшы дип табылган театр коллективларын бүләкләү өчен акча чыгымнарын табуны район финанс-бюджет Палатасына тәкъдим итәргә.

Саба муниципаль район башлыгы Р.Н.Минниханов

Саба муниципаль район башлыгының
2012 елның ___12 ноябрь___
___1.18-п___ карары белән расланды

“Театр фестивале”нең оештыру комиссиясенең
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Шәрәфиев Т.Г. | – Саба муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, оештыру комиссиясе рәисе |
| Гәрәев А.Н. | - Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Зиннуров А.М. | - район мәдәният йорты директоры (килешү буенча) |
| Исмәгыйлов Р.Р. | - “ Саба таңнары” газетасы редакторы (килешү буенча) |
| Кәримов М.Р. | - мәдәният йорты өлкән методисты (килешү буенча) |
| Мөбәрәкова Ә.Г. | - “ Саба дулкыннары” телерадиокомпаниясе директоры (килешү буенча) |
| Хаҗиева Р.И. | - Шәмәрдән мәдәният йорты директоры (килешү буенча) |
| Хәсәнов Р.М. | - Саба шәһәр җирлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Хафизов М.Г. | - мәдәният бүлеге начальнигы |

Саба муниципаль район башлыгының
2012 елның 12 ноябрь
118-п карары белән расланды

## Саба авыл җирлекләрендә Шәүкәт Биктимеров истәлегенә багышланган “ Театр фестивале”н үткәрү графигы

| № | Спектакль куючы авыл җирлеге | Үткәрү көне | Үткәрү урыны |
|---|---|---|---|
| 1. | Олы Нырты авыл җирлеге<br><br>Арташ авыл җирлеге | 13.01.2013<br><br>20.01.2013 | 2 БасуАрташ мәдәният йорты.<br>Олы Нырты мәдәният йорты. |
| 2. | Иске Икшермә авыл җирлеге<br><br>Кибәче авыл җирлеге | 27.01.2013<br><br>3.02.2013 | Кибәче авыл клубы<br><br>Иске Икшермә мәдәният йорты |
| 3. | Түбән Шытсу авыл җирлеге<br><br>Сатыш авыл җирлеге | 10.02.2013<br><br>17.02.2013 | Сатыш мәдәният йорты<br>Түбән Шытсу мәдәният йорты |
| 4. | Иске Мичән авыл җирлеге<br><br>Кече Шыңар авыл җирлеге | 24.02.2013<br><br>3.03.2013. | Кече Шыңар мәдәният йорты<br><br>Иске Мичән мәдәният йорты |
| 5. | Явлаштау авыл җирлеге<br><br>Шекше авыл җирлеге | 10.03.2013<br><br>17.03.2013 | Шекше мәдәният йорты.<br>Явлаштау мәдәният йорты. |
| 6. | Эзмә авыл җирлеге<br><br>Тимершык авыл җирлеге | 24.03.2013<br><br>31.03.2013 | Тимершык мәдәният йорты.<br>Эзмә мәдәният йорты. |
| 7. | Югары Симет авыл җирлеге<br><br>Курсабаш авыл җирлеге | 7.04.2013<br><br>14.04.2013 | Курсабаш мәдәният йорты<br><br>Югары Симет мәдәният йорты. |
| 8. | Килдебәк авыл җирлеге<br><br>Юлбат авыл җирлеге | 21.04.2013<br><br>28 .04.2013 | Юлбат мәдәният йорты.<br><br>Килдебәк мәдәният йорты |
| 9. | Лесхоз авыл җирлеге<br><br>Иштуган авыл җирлеге | 5.05.2013<br><br>12.05.2013 | Иштуган мәдәният йорты<br><br>Лесхоз мәдәният йорты. |

Саба муниципаль район башлыгының
2012 елның ___12 ноябрь___
___118-п___карары белән расланды

Саба шәһәр җирлегендә Шәүкәт Биктимеров истәлегенә багышланган
“ Театр фестивале”н үткәрү графигы

| № п/п | Предприятие исемлеге | Спектакль булачак көн |
|---|---|---|
| 1. | Саба аграр көллияте | 18.01.2013 |
| 2. | Саба гимназиясе | 19.01.2013 |
| 3. | Саба кадет- интернат мәктәбе | 25.01.2013 |
| 4. | “ Вамин Татарстан” ААЖ “ ВАМИН Саба”филиалы | 26.01.2013 |
| 5. | “ Сабагаз” эксплуатация җитештерү идарәсе | 01.02.2013 |
| 6. | Район үзәк шифаханәсе | 02.02.2013 |
| 7. | “ Торак коммуналь хуҗалыгының Саба күптармаклы җитештерү предприятиесе” ААҖ | 8.02.2013 |
| 8. | Җаваплылыгы чикләнгән “ Сабаагрохим” җәмгыяте | 9.02.2013 |
| 9. | Россия эчке эшләр министрлыгының “Саба” муниципальара бүлеге | 15.02.2013 |
| 10. | “ Татавтодор” ААЖ Саба филиалы | 16.02.2013 |
| 11. | Җаваплылыгы чикләнгән “ Саба МТС” җәмгыяте | 22.02.2013 |
| 12. | Район почта элемтәсе идарәсе<br>Район электр элемтәсе узелы | 23.02.2013 |
| 13. | Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасының 10 нчы номерлы районара инспекциясе | 01.03.2013 |
| 14. | Социаль яклау идарәсе | 02.03.2013 |
| 15. | ТР буенча Федераль казначылык идарәсенең Саба районы буенча бүлеге<br>Саба район финанс-бюджет Палатасы<br>ТР финанс министрлыгының казначылык департаментының Саба районы территория бүлекчәсе | 08.03.2013 |
| 16. | “Саба дулкыннары” ТРК | 09.03.2013 |
| 17. | Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемология үзәгенең Саба районы филиалы | 15.03.2013 |
| 18. | Район электр челтәре (РЭС)<br>Энергосбыт | 16.03.2013 |
| 19. | ТР Саба муниципаль районы “ Олимп” балалар – яшүсмерләр спорт мәктәбе<br>“Спорт комплекс” муниципаль учреждениеесе<br>ТР Саба муниципаль районының “ Саба йөзү бассейны физкультура сәламәтдерү комплексы” муниципаль учреждениесе | 22.03.2013 |
| 20. | Район кулланучылар җәмгыяте берлеге идарәсе | 23.03.2013 |
| 21. | Җаваплылыгы чикләнгән “Рамазан” җәмгыяте<br>Җаваплылыгы чикләнгән “Яшен” җәмгыяте | 29.03.2013 |

| | | |
|---|---|---|
| 22. | РФ пенсия фонды идарәсенең ТР Саба һәм Теләче районнары буенча идарәсе | 30.03.2013 |
| 23. | “Ак Барс” ачык акционерлык җәмгыятенең Казан филиалы Саба өстәмә офисы<br>Россия саклык банкы ачык акционерлык җәмгыятенең 4642 нче номерлы Саба бүлекчәсе | 5.04.2013 |
| | **ШӘМӘРДӘН ЗОНАСЫ БУЕНЧА** | |
| 1. | Шәмәрдән лицее | 4.01.2013 |
| 2. | Шәмәрдән шифаханәсе | 11.01.2013 |
| 3. | Шәмәрдән магистраль газүткәргечләр линия производство идарәсе | 18.01.2013 |
| 4. | “Торак коммуналь хуҗалыгының Шәмәрдән күптармаклы җитештерү предприятиесе” ААҖ | 25.01.2013 |
| 5. | Җаваплылыгы чикләнгән “ ТАТМИТАгро” җәмгыяте | 01.02.2013 |
| 6. | “Шәмәрдән ашлык кабул итү предприятиесе” ААҖ | 08.02.2013 |
| 7. | Югары Утар балалар йорты-интернаты | 15.03.2013 |
| 8. | “Татнефтепродукт” ААҖ “ Шәмәрдәннефтепродукт” филиалы | 22.03.2013 |

Саба муниципаль район башлыгының
2012 елның 12 гыйнвар
118-п карары белән расланды

# Шәүкәт Биктимеров истәлегенә багышланган “ Театр фестивале”н үткәрү нигезләмәсе

1. “Театр фестивале” 2013 елның январь, февраль, март, апрель, май айларында үз җирлекләренә кергән оешма, предприятие, учреждениеләр катнашында авыл клубларында, мәдәният йортларында, район һәм Шәмәрдән мәдәният йортларында үтә.

2. Спектакль бәяләү өчен жюри составы мәдәният белгечләре катнашында төзелә. “Театр фестивале” бәйге рәвешендә үткәрелә.

3. Чыгыш ясау вакыты һәр коллектив өчен бер сәгать ярым яисә ике сәгать бирелә. Яхшы дип табылган спектакльләр 5 (биш) баллы система белән бәяләнә.

4. Уңышлы дип саналган спектакльләр май аенда район үзәгендә һәм Шәмәрдәндә булачак фестивальнең йомгаклау кичәсенә чакырыла.

5. Авыл җирлекләренә кергән һәр авыл клубы, мәдәният йортлары аерым спектакль белән чыгыш ясап, иң яхшы дигән коллектив театр фестивalenә тәкъдим ителә.